Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Сходнево-Чертанла авылында гражданнар җыены

КАРАРЫ

2022 елның 19 ноябре №2

**2023 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Куакбаш авыл җирлегенең Сходнево-Чертанла авылы гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турында**

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлеге Сходнево-Чертанла авылы гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2023 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Куакбаш авыл җирлеге Сходнево-Чертанла авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге формада укучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- Сходнево-Чертанла авылында (Ирек ур., Кутузов ур.) юлларга вак таш җәеп чокырларны ремонтлау;
- Сходнево-Чертанла авылындагы (Пушкин ур., Ирек ур., Кутузов ур.) юлларны кардан чистарту.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Куакбаш авылы, Куакбаш авылы, Карл Маркс урамы, 15 йорт адресы буенча урнашкан җирле үзидарә бинасында, Сходнево-Чертанлы авылы Ирек урамы, 5а буенча урнашкан авыл клубы, Чүте авылында Тынычлык урамы 8А буенча урнашкан авыл клубы бинасында урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы «Куакбаш авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Р.Әхмәтҗанова